# КАРАР

**07 декабрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Починок Кучук авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 7 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I һәм II төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Починок Кучук авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:
юлларны кардан чистарту;
- Мәктәп урамы коесын төзекләндерү;
- Починок Кучук авылында чокырларны ямау эше;
- янгын рукавлары сатып алу һәм урнаштыру;
- Починок Кучук авылында мөселман зиратын коймалау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 309 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 160кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 160 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок Кукчук авыл җирлеге Починок Кучук авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: ««I һәм II төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан

Республикасы Кукмара муниципаль районы Починок Кучук авыл җирлегенең Починок Кучук авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 750 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Мәктәп урамындагы коены төзекләндерү (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү).
- Починок Кучук авылында, вак таш түшәп, юлларда чокырларны ямау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
-Күл буе урамына янгын гидрантлары, колонкалары һәм рукавлары сатып алу, урнаштыру (смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
-Починок Кучук авылында мөселман зиратын койма белән әйләндереп алу (материал сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Починок-Кучук
авыл җирлеге башлыгы

Ф.А.Гайнетдинов

ОГРН 1021607752924 ИНН 1623001741